**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Фосфорорганик химия өлкәсендә халыкара Арбузов премиясен бирү комитеты составына үзгәреш кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Фосфорорганик химия өлкәсендә халыкара Арбузов премиясен бирү комитеты составын раслау турында» 2006 елның 18 августындагы ПУ-313 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 25 сентябрендәге ПУ-929 номерлы, 2014 елның 20 декабрендәге ПУ-1160 номерлы, 2017 елның 8 апрелендәге ПУ-297 номерлы, 2019 елның 28 мартындагы ПУ-186 номерлы, 2021 елның 14 июлендәге ПУ-579 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 11 июлендәге 484 номерлы һәм 2024 елның 5 августындагы 592 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Фосфорорганик химия өлкәсендә халыкара Арбузов премиясен бирү комитеты (алга таба – Комитет) составына, Комитет әгъзасы Ә.М. Мазһаровның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә: «Идел буе углеводород чималы фәнни-тикшеренү институты» гавами булмаган акционер җәмгыяте баш фәнни хезмәткәре – җәмгыять директоры киңәшчесе, техник фәннәр докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2025 ел, 06 март
№ 184